ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫ
Ң
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

13.03.2018______ № 29-од___

г. Казань

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының ведомство аерымлык тамгаларын гамәлгә кую турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 27.07.2004 № 79-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 16.01.2003 № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 09.08.2016 №541 карары белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәнең 4.1.19 пункты нигезендә Татарстан Республикасы архив эшенә зур шәхси өлеш керткән затларны, шулай ук нәтиҗәле граждан хезмәте һәм Россия Федерациясе Архив фонды һәм Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны тәэмин итү, дәүләт исәбенә алу, туплау һәм алардан файдалану эшендә югары казанышлар өчен мораль бүләкләү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының түбәндәге ведомство аерымлык тамгаларын гамәлгә куярга:

– Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Мактау грамотасын.

– Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Рәхмәтен.

2. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәне.

2.2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Рәхмәте турындагы нигезләмәне.

2.3. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләүгә тәкъдим итү формасын.

3. Финанс-икътисадый бүлек башлыгы ел саен Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының ведомство аерымлык тамгаларын әзерләүгә чыгымнар карарга тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитетының 13.03.2018 ел № 29-од
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының**
**Архив эше буенча дәүләт комитетының**
**Мактау грамотасы турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Мактау грамотасы (алга таба – Мактау грамотасы) белән түбәндәгеләр бүләкләнә:

- Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Дәүләт архив комитеты) дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм хезмәткәрләре – нәтиҗәле эш, аерым әһәмияттәге һәм катлаулы биремнәрне үтәгән, шулай ук күп еллык намуслы хезмәт өчен;

- ТР Дәүләт архив комитеты ведомствосындагы оешмаларның, Татарстан Республикасының һәм муниципаль берәмлекләрнең архив органнарының һәм архив учреждениеләренең, ведомство архивларының һәм оешмаларның эшләр алып бару хезмәтләренең әлеге оешмада һәм хезмәттә кимендә 5 ел эшләгән хезмәткәрләре, шулай ук фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклауны тәэмин итүдә, дәүләт исәбенә алуда, туплауда һәм алардан файдалануны оештыруда актив катнашкан һәм бу эшчәнлектә архив учреждениеләренә актив ярдәм күрсәткән иҗтимагый оешмалар вәкилләре һәм бүтән затлар. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә аерым затлар да, шулай ук архив учреждениеләренең хезмәт коллективлары да һәм алда санап үтелгән башка оешмалар да тәкъдим ителергә мөмкин.

2. Мактау грамотасы бүләкләнә:

- Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклауны тәэмин итүдә, туплауда, дәүләт исәбенә алуда һәм алардан файдалануны оештыруда актив катнашкан өчен;

- Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклауны тәэмин итү, туплау, дәүләт исәбенә алуны һәм алардан файдалануны оештыру эшчәнлегендә архив учреждениеләренә актив ярдәм күрсәткән өчен;

- архив эшчәнлегенең аерым юнәлешләрендә күп еллык намуслы хезмәт һәм эштәге уңышлар өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Архив фонды документларын оешмада ведомство тарафыннан саклауны оештырудагы, оешмаларның эшләр алып баруда документларны оештырудагы уңышлар өчен.

3. Дәүләт граждан хезмәткәрләрен Мактау грамотасы белән бүләкләү – эш стажын исәпкә алмыйча, шул исәптән дәүләт хезмәте стажын да исәпкә алмыйча гамәлгә ашырыла, бүтән затлар өчен – тармакта кимендә 5 ел эш стажы булганда.

4. ТР Дәүләт архив комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләү өч елдан да иртәрәк булмаган яңа казанышлар өчен гамәлгә ашырыла.

5. ТР Дәүләт архив комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карар бүләкләүгә тәкъдим итүче төп эш урыныннан үтенечнамә буенча ТР Дәүләт архив комитеты коллегиясе тарафыннан кабул ителә. Үтенечнамә ТР Дәүләт архив комитеты Рәисе исеменә җибәрелә һәм 13.03.2018 № 29-од боерыгы белән расланган форма буенча бүләкләү битендә рәсмиләштерелә. Хезмәткәрнең характеристикасында архив эше өлкәсендәге программаларны, проектларны, чараларны гамәлгә ашыруга шәхси өлеше турында конкрет белешмәләр чагылдырыла, соңгы 5 елдагы эш нәтиҗәләренә басым ясала.

Үтенечнамәгә түбәндәгеләр кушып бирелә:

- бүләкләүгә тәкъдим ителүче затның паспортының беренче бите күчермәсе;
- коллектив җыелышы беркетмәсеннән өземтә.

6. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә оешманың бүләкләүгә тәкъдим итү турында коллегиаль органы карары кушып бирелә.

7. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карар түбәндәгеләр керткән үтенечнамә буенча ТР Дәүләт архив комитеты коллегиясе ризалыгы белән ТР Дәүләт архив комитеты Рәисе тарафыннан кабул ителә:

- архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы субъектларының вәкаләтле башкарма органнары;
- ТР Дәүләт архив комитеты ведомствосындагы оешмалар җитәкчеләре;
- ТР Дәүләт архив комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләре.

Мактау грамотасы белән бүләкләү ТР Дәүләт архив комитеты Рәисе тарафыннан имзаланган ТР Дәүләт архив комитеты боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Мактау грамотасын тапшыру бүләкләнүченең эш урыны буенча тантаналы төстә гамәлгә ашырыла.

9. Мактау грамотасы белән бүләкләнгәннең хезмәт кенәгәсенә, ТР Дәүләт архив комитеты боерыгы датасы һәм номеры күрсәтелеп, тиешле язма ясала.

10. Мактау грамотасы дубликаты бирелми. ТР Дәүләт архив комитеты Мактау грамотасын югалткан очракта, бүләкләү турындагы боерыктан өземтә бирелә, ул мөһер белән таныклана.

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитетының 13.03.2018 ел № 29-од
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының**
**Архив эше буенча дәүләт комитетының**
**Рәхмәте турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Рәхмәте (алга таба – Рәхмәте) белән түбәндәгеләр бүләкләнә:

- Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Дәүләт архив комитеты) дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм хезмәткәрләре – нәтиҗәле эш, аерым әһәмияттәге һәм катлаулы биремнәрне үтәгән, шулай ук күп еллык намуслы хезмәт өчен;

- ТР Дәүләт архив комитеты ведомствосындагы оешмаларның, Татарстан Республикасының һәм муниципаль берәмлекләрнең архив органнарының һәм архив учреждениеләренең, ведомство архивларының һәм оешмаларның эшләр алып бару хезмәтләренең әлеге оешмада һәм хезмәттә кимендә 3 ел эшләгән хезмәткәрләре, шулай ук фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклауны тәэмин итүдә, дәүләт исәбенә алуда, туплауда һәм алардан файдалануны оештыруда актив катнашкан һәм бу эшчәнлектә архив учреждениеләренә актив ярдәм күрсәткән иҗтимагый оешмалар вәкилләре һәм бүтән затлар. Рәхмәт белән бүләкләүгә аерым затлар да, шулай ук архив учреждениеләренең хезмәт коллективлары да һәм алда санап үтелгән башка оешмалар да тәкъдим ителергә мөмкин.

2. Рәхмәт белән бүләкләнә:

- Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклауны тәэмин итүдә, туплауда, дәүләт исәбенә алуда һәм алардан файдалануны оештыруда актив катнашкан өчен;

- Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклауны тәэмин итү, туплау, дәүләт исәбенә алуны һәм алардан файдалануны оештыру эшчәнлегендә архив учреждениеләренә актив ярдәм күрсәткән өчен;

- архив эшчәнлегенең аерым юнәлешләрендә күп еллык намуслы хезмәт һәм эштәге уңышлар өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Архив фонды документларын оешмада ведомство тарафыннан саклауны оештырудагы, оешмаларның эшләр алып баруда документларны оештырудагы уңышлар өчен.

3. Дәүләт граждан хезмәткәрләрен Рәхмәт белән бүләкләү – эш стажын исәпкә алмыйча, шул исәптән дәүләт хезмәте стажын исәпкә алмыйча гамәлгә ашырыла, бүтән затлар өчен – тармакта кимендә 3 ел эш стажы булганда.

4. Рәхмәт белән бүләкләү өч елдан да иртәрәк булмаган яңа казанышлар өчен гамәлгә ашырыла.

5. ТР Дәүләт архив комитеты Рәхмәте белән бүләкләү турындагы карар бүләкләүгә тәкъдим итүче төп эш урыныннан үтенечнамә буенча ТР Дәүләт архив комитеты коллегиясе тарафыннан кабул ителә. Үтенечнамә ТР Дәүләт архив комитеты Рәисе исеменә җибәрелә һәм 13.03.2018 № 29-од боерыгы белән расланган форма буенча бүләкләү битендә рәсмиләштерелә.

Хезмәткәрнең характеристикасында архив эше өлкәсендәге программаларны, проектларны, чараларны гамәлгә ашыруга шәхси өлеше турында конкрет белешмәләр чагылдырыла, соңгы 3 елдагы эш нәтиҗәләренә басым ясала.

Үтенечнамәгә түбәндәгеләр кушып бирелә:

- бүләкләүгә тәкъдим ителүче затның паспортының беренче бите күчермәсе;

- коллектив җыелышы беркетмәсеннән өземтә.

6. Рәхмәт белән бүләкләү турындагы карар түбәндәгеләр керткән үтенечнамә буенча ТР Дәүләт архив комитеты коллегиясе ризалыгы белән ТР Дәүләт архив комитеты Рәисе тарафыннан кабул ителә:

- архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы субъектларының вәкаләтле башкарма органнары;

- ТР Дәүләт архив комитеты ведомствосындагы оешмалар җитәкчеләре;

- ТР Дәүләт архив комитеты структур бүлекчәләре җитәкчеләре.

Рәхмәт белән бүләкләү ТР Дәүләт архив комитеты Рәисе тарафыннан имзаланган ТР Дәүләт архив комитеты боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Рәхмәтне тапшыру бүләкләнүченең эш урыны буенча тантаналы төстә гамәлгә ашырыла.

9. Рәхмәт белән бүләкләнгәннең хезмәт кенәгәсенә, ТР Дәүләт архив комитеты боерыгы датасы һәм номеры күрсәтелеп, тиешле язма ясала.

10. Рәхмәт дубликаты бирелми. ТР Дәүләт архив комитетының Рәхмәтен югалткан очракта, бүләкләү турындагы боерыктан өземтә бирелә, ул мөһер белән таныклана.

Кушымта
Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 13.03.2018 ел № 29-од боерыгы белән расланды

БҮЛӘКЛӘҮ БИТЕ

______________________________________________________________

(Татарстан Республикасы субъекты)

______________________________________________________________

(ведомство бүләкләве төре)

1. Фамилиясе_____________________________________________________
Исеме____________________ Атасының исеме____________________________
2. Вазыйфасы, эш урыны

______________________________________________________________

(оешманың төгәл атамасы, оештыру-хокукый рәвешен һәм вазыйфасын күрсәтеп)

________________________________________________________________
____________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

3. Җенесе ________________________
4. Туган датасы ____________________________
5. Туган урыны______________________________________________________

______________________________________________________________

(республика, край, өлкә, шәһәр, район, поселок, авыл)

________________________________________________________________
_______

6. Белеме

________________________________________________________________
____________________________________________________________

(уку йортының атамасы, тәмамлау елы)

______________________________________________________________
______________________________________________________________

7. Нинди дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм бүләкләү даталары

________________________________________________________________
________________________________________________________________
__________________________________________________________
______________________________________________________________

8. Нинди ведомство, төбәк бүләкләре белән бүләкләнгән һәм бүләкләү даталары

______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

9. Өенең адресы

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

10. Гомуми эш стажы _______________ Тармактагы эш стажы _________________

Коллективтагы эш стажы_______________________________________________________________

11. Хезмәт эшчәнлеге, эшкә керү һәм китү даталарын, вазыйфасын һәм оешма атамасын күрсәтеп

| Ай һәм ел | | Вазыйфасы, предприятиене, учреждениене, оешманы, шулай ук министрлыкны (ведомствоны) күрсәтеп | Предприятие, учреждение, оешма урнашкан җир |
|---|---|---|---|
| эшкә керү | эштән китү | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

12. Характеристика, бүләкләүгә тәкъдим ителүченең конкрет казанышларын күрсәтеп

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

___________________________________________________кандидатурасы хезмәт коллективының гомуми җыелышы, коллегиясе тарафыннан тәкъдим ителде (фикер алышу датасы, беркетмә №)

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

Оешма җитәкчесе Җыелыш (коллегия) рәисе

____________________ ________________________________

(имза) (имза)

________________________________ ________________________________

(фамилиясе, инициаллары) (фамилиясе, инициаллары)

М.У.

"__" ________________ ел